**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Олы Яңасала авылында гражданнардан 2025 елда үзара салым кертү турында**
**КАРАРы**

**19 нче ноябрь 2024 ел** **№ 1**

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Яңасала авылында гражданнар җыены **карар итте**:

1. Үзара салым 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Яңасала авылы территорясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1200(Бер мең ике йөз) сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;**

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;**

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;**

**- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.**

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы Үзәк ур., 1;
- ТР Кама Тамагы районы Шәпкә авылы,Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Шиһабеев